КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 июль г.Казань № 840

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинетының кайбер карарларына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 ел, 2 ноябрь, ТРЗ-73 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2013 ел, 2 февраль, 69 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 февраль, 103 нче, 2016 ел, 15 август, 563 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы территориясендә түләүсез юридик ярдәм дәүләт системасына шул исәптән Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указына 2 нче кушымтаның II, III һәм IV бүлекләрендә күрсәтелгән республика башкарма хакимият органнары, шулай ук аларга буйсынучы учреждениеләр керә дип билгеләргә.»;

3 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 ел, 4 апрель, 225 нче карарына (Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 ноябрь, 844 нче, 2019 ел, 09 сентябрь, 811 нче, 2023 ел, 21 март, 310 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата бердәм таләпләрдә:

исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органны тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 25 май, 298 нче; 2018 ел, 21 май, 384 нче; 2019 ел, 25 гыйнвар, 38 нче; 2020 ел, 12 март, 187 нче; 2020 ел, 21 сентябрь, 850 нче; 2021 ел, 15 февраль, 81 нче; 2021 ел, 21 июль, 636 нчы; 2021 ел, 23 октябрь, 998 нче, 2022 ел, 2 сентябрь, 945 нче, 2023 ел, 23 май, 628 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында нигезләмәгә, 6 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1285 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 декабрь, 1422 нче, 2023 ел, 20 март, 286 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегиядә:

I бүлектә:

унөченче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

утыз сигезенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның 2019 елның 25 сентябрендәге ПУ-574 номерлы Указы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын үзгәртеп кору турында» 2019 елның 25 сентябрендәге ПУ-574 номерлы Указы» сүзләренә алмаштырырга;

II бүлектә:

2.2 бүлекчәнең икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 бүлекчәнең дүртенче абзацында «башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 бүлекчәдә:

унынчы абзацта «республика башкарма хакимияте органнары һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләр» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары һәм алар ведомствосына буйсынучы учреждениеләр» сүзләренә алмаштырырга;

унҗиденче абзацта «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

V бүлекнең 5.3 бүлекчәсендә:

тугызынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

VII бүлектә:

7.1 бүлекчәнең унберенче абзацында «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

7.4 бүлекчәнең дүртенче абзацында «башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

VIII бүлекнең 8.1 бүлекчәсендәге егерме өченче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

IX бүлекнең җиденче абзацында «башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегиягә кушымтада:

1.1 пунктта:

«дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үз эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру, шул исәптән «Интернет» челтәрендә» юлының 4 графасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

«Интернет» челтәрендә норматив хокукый актлар проектларын урнаштыру» юлының 4 графасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

«Интернет» челтәрендә норматив хокукый актлар проектларын урнаштыру» юлының 5 графасында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктның «дәүләт телләрендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү» юлының 4 графасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктның 4 графасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның «Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алу хокукына конкурсларда, шулай ук гражданлык бердәмлеген ныгытуга һәм милләтара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләүгә юнәлдерелгән коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларның иҗтимагый проектларына ярдәм итүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга һәм министрлыклар һәм ведомстволарның башка конкурсларында дини оешмаларның катнашуына ярдәм итү юлы белән социаль проектларга һәм дини берләшмәләр инициативаларына ярдәм итү» юлының 3 графасында «министрлыклар һәм ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктның «ведомство буйсынуындагы оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү, систематик анализ ясау һәм аның нәтиҗәләре буенча аларның түләү сәләтен саклап калуга һәм хезмәт хакын түләү буенча бурычларны булдырмауга юнәлдерелгән превентив характердагы чаралар кабул итү, кирәк булганда - түләргә сәләтсез оешмаларга карата бөлгенлек процедураларын, аларны финанс яктан савыктыру процедураларын да кертеп, гамәлгә кертү буенча үз вакытында чаралар күрү» юлының 4 графасында»Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

6.1 пунктта:

3 графада «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4 графада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

8.2 пунктның «авыл җирлегендә социаль яклanмаган, аз керемле гражданнарны һәм авыр тормыш хәлендә калган гражданнарны хокукый ярдәм күрсәтү өчен ерактан торып (видеоконференция режимында) кабул итүне оештыру һәм үткәрү» юлының

4 графасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

8.5 пунктта:

«Татарстан Республикасы министрлыклары, ведомстволары, учреждениеләре сайтларында аларның эшчәнлеге өлкәсендә барлыкка килә торган хокукый проблемалар буенча материаллар урнаштыру» юлының 3 графасында «министрлыклар, ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы министрлыклары, ведомстволары, учреждениеләре сайтларында аларның эшчәнлеге өлкәсендә барлыкка килә торган хокукый проблемалар буенча материаллар урнаштыру» юлының 4 графасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин